

Мордовия Республикасы Матбугат үзәгендә 2023 елнын җәйге янгын куркынычсызлыгы нәтиҗәләренә һәм көзге-кышкы чорда янгын куркынычсызлыгын профилактикалауга багышланган матбугат конференциясе узды.

Чарада теманы ачыклап түбәндәге спикерлар чыгыш ясады: Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын РМ буенча Баш идарәсе начальнигы урынбасары, эчке эшләр полковнигы Болталин Александр Александрович; Мордовия ЦГМС ФГБУ Югары Волга УГМС филиалы җитәкчесе Хлевина Светлана Евгеньевна; Урман, аучылык хуҗалыгы һәм табигатьтән файдалану министры Галиуллин Адель Ростәм улы; Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча дәүләт комитеты рәисе Наумов Андрей Геннадьевич.      Быел Мордовиядә янгыннар саны 27,2% ка арткан. “Аларнын яртысыннан артыгы апрель аенда теркәлгән - 966 янгын. Ләкин вакытында кабул ителгән профилактик чаралар ярдәмендә хәлне тотрыклыландыруга ирешелде. Май башыннан октябрь ахырына кадәр 919 янгын була. Шул ук вакытта 2023 елда төбәк территориясендә урман янгыннары булмавын ассызык-лыйм”, - диде Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын РМ буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасары Александр Александрович Болталин. Ул билгеләп үткәнчә, көзге-кышкы янгын куркынычсызлыгы чоры башланганнан бирле Дәүләт янгын күзәтчелеге хезмәткәрләре тарафыннан 435 профилактик чара, гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияләрнен 10 утырышы оештырылган һәм үткәрелгән инде. Тагы спикер билгеләп үткәнчә, хәзер Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын Мордовия Республикасы буенча Баш идарәсе кораллануында торган техника һәм җиһазлар әзерләү буенча актив эш алып барыла: “Кышкы вакытта Мордовия Республикасы территориясендә автомобиль юлларында кышкы тыгынлык очрагында 25 стационар җылыту пунк-ты, 6 күчмә җылыту пункты һәм мобиль пункт каралган. Баш идарә көчләре һәм чаралары мөмкин булган гадәттән тыш хәлләргә җавап бирергә әзер”.

Мордовиядә фаразланган һава шартлары турында Мордовиянен Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы үзәге начальнигы Светлана Евгеньевна Хлевина сөйләде: “Хәзер без табигатьтә температура артуын күзәтәбез. Бу тенденция ноябрь уртасына кадәр дәвам итәчәк. Җылы һава массаларынын хәрәкәте эрүгә китерә. Әмма бу чор явым-төшемнәрнен сыеклыктан каты хәлгә күчүе, бозлавык һәм кар өермәсе кебек күренешләр барлыкка килүе белән бергә бара, шуна күрә уяу һәм бик сак булырга кирәк”.

“Мордовия республикасы - Идел буе федераль округынын (ПФО) быел урман фонды җирләрендә бер генә урман янгыны да булмаган бердәнбер төбәге. Соңгы 20 елда беренче тапкыр. Без мондый күрсәткечкә кулланылган чаралар, вакытында җавап бирү һәм грамоталы эш ярдәмендә ирешә алдык. Янгын куркынычынын 4 һәм 5 классына җиткәндә гражданнарнын урманнарда булуларын һәм аларга транспорт чараларынын керүләрен чикләү кертелде, бөтен республика буенча һәвәскәрләр һәм спорт ауларын гамәлгә ашыру тыелды, янгынга каршы чаралар комплексы үтәлде. 24 видеокамера ярдәмендә республика урманнары даими контрольдә тотыла. Ел ахырына кадәр тагын 3 видеокамера урнаштыру планлаштырыла”, - дип билгеләп үтте төбәкнен Урман, аучылык

хужалыгы һәм табигатьтән файдалану министры Адель Ростәм улы Галиуллин.
Мордовия Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча Дәvләт комитеты рәисе Андрей Геннадьевич Наумов халыкны торле хәлләргә әзерләv турында чыгыш ясады: “Ел дәвамында республика территориясендә гражданнар оборонасы буенча торле чаралар vткәреләә. Халыкны, гадәттән тыш хәл турында сигнал килгәч, ничек эш итәргә кирәклеге турында ойрәтәләр. Беренче чиратта бу жайлаштырылган биналарга яшеренv белән бәйле. Безнен максат - кешене әйләнә-тирә мохит vзгәрvгә әзерләv.
Козге-кышкы чорда йортларда һәм фатирларда янгын чыгу куркынычы арта. Ин еш очрый торган сәбәпләр - мич жылыту яки электр чыбыклары житешсезлеге. Янгыннар санын киметv очен, гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре торак секторны урап узалар һәм социаль учреждениеләргә йориләр, гражданнар белән әнгәмәләр vткәрәләр һәм янгын куркынычсызлыгы чараларын vтәv турында профилактик чаралар vткәрәләр.
Тик кvпчелегебез куркынычсызлык турында уйлап бетерми, салкын карый. Кемдер, минем белән мондый хәл килеп чыкмас, дип уйлап ялгыша. Хәтта яна фатирларга урнаштырылган хәбәр итv жайланмаларын сvтеп алып куючылар да бар. Югыйсә бу беренче чиратта vзен һәм якыннарын очен кирәк. Кызганыч, аяныч хәлләр еш очрый, ә ялкын телләре ялгышуны кичерми.
Хормәтле гражданнар, исегезгә тошерәбез, куркынычсызлык мәсьәлә-ләренә игътибарлы караш - кешеләрнен тормышы һәм сәламәтлеге, молкәтнен сакланышы һәм табигый байлыкны саклау очен гарантия! Yзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз - янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен vтәгез!”
Янгын ялгышларны кичерми.

**Наилә НАСЫРОВА**